Республика Татарстан
Глава Татарско-Челнинского сельского поселения
Менделеевского муниципального района
423641, Менделеевский район,
с.Татарские Ченлны,
ул. Победы, д 3А

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
ТатарЧаллысы авыл җирлеге
Башлыгы
423641, Менделеевск районы, Татар Чаллысы авылы,
Победа урамы, 3А

тел./факс 8/85549/3-42-23, E-mail: Tcn.men@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**2021 нче елның 10 нчы декабрендәге 5 нче номерлы КАРАРЫ**

Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлегенен Татар Чаллысы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыены үткәрү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131 нче номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 25.1, 56 ст., 2004 елның 28 июлендәге 45 нче номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Уставының 22 ст. нигезендә

КАРАР ИТӘМ:

1. 2021 елның 20 декабрендә 12 сәгать 00 минутта Татар Чаллысы авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2021 елның 20 декабрендә 14 сәгать 00 минутта Татар Чаллысы авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча икенче этабын билгеләргә.

3. Җыеннарның барлык этапларын үткәрү урыны итеп Татар Чаллысы авылы, Җиңү урамы, 3А йорты адресы белән урнашкан Татар Чаллысы авыл мәдәният йортын билгеләргә

Татар Чаллысы халкы исемлеген җыеннар этапларына бүлү территориаль билге буенча киләсе тәртиптә башкарыла:

Беренче  этап: Яшел урам 1 нче йорттан 8 нче йотрка кадәр, Төньяк урам 1 нче йорттан 4 нче йортка кадәр, Җиңү урамы 1 нче йорттан 12 нче йортка кадәр, Мәктәп урамы 3 нче йорттан 15 нче йортка кадәр

Икенче этап: Тынычлык урамы 1 нче йорттан 29 нчы йортка кадәр, Яшьләр урамы 1 нче йорттан 22 нче йортка кадәр,  Мохначёв урамы 1 нче йорттан 9 нчы йортка кадәр.

Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

**1.** «Сез  2022 елда Менделеевск муниципаль районы  Татар Чаллысы авыл җирлегенең Татар Чаллысы авылы территориясенддә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндез уку формасындагы студентлардан тыш, үзара салым акчаларын 500 сум күләмендә,  җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә

**- Авыл җирлеге территориясен төзекләндерү (үлән чабу, балалар мәйданчыгын киртәләп алу өчен материал сатып алу).**
**- Урам яктырткычлары урнаштыру.**
**- Бензин роторлы кар чистарткычын сатып алу.**

“Риза”                                        “каршы”

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып 3 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында Татар Чаллысы авыл җирлеге бүлегендә  урнаштыру юлы белән игълан итәргә. www.mendeleevsk.tatar.ru
4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы                                  Кузнецова Т.П